СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

«14» ноября 2024г. — №2-38

## «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләрне хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

3. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2018 елның 05 июнендәге 1-31 номерлы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны 2024 елның 11декабрендә 11.00 сәг.; Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Тәкәнеш авылы, Банк урамы, 17 йорт адресы буенча дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карарына

үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Хәмизуллин Р.Ж. – 5 нче бермандатлы сайлау округы депутаты, төркем җитәкчесе;

2) Гайнуллин Р.М. – 6 нче бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Гарипов И.Х.– 9 нчы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Совет карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен һәм Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы Р.Ж. Хәмизуллинга йөкләргә.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы рәисе / Р.Ж.Хәмизуллин/

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге
Советының
14 ноябрь, 2024 ел, №2-38
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелүче үзгәрешләр

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру»;
2. Уставның 19 статьясындагы 5 пунктының 2 абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9_2 пунктларында»сүзләренә алмаштырырга.;
3. 22 статьюяга түбәндәге эчтәлектәге 2.2. өлеш өстәргә:
«2.2. Әлеге статьяның 3 өлешендәге 3 пунктында каралган мәсьәләләрне хәл иткәндә гражданнар җыенында шулай ук гражданнар җыенын уздыру көненә 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары, әгәр бу Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән булса, катнаша ала.»;
3. Часть 41 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:
«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;
47 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:
«18) аның чит ил агенты статусын алуы;»;
6. 50 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыра.».

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге
Советының
14 ноябрь, 2024 ел, № 2-38
карарына 2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре түбәндәге Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Тәкәнеш авылы, Банк урамы, 17 йорт адресы буенча, (885563) 2-63-21 тел/факс буенча, e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru аша Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советына түбәндәге төзәтмәләр таблицасы формасында фамилия, исем, әтисенең исеме, туган елын , яшәү адресын күрсәтеп, кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.А и., адрес, Эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә әлеге карарны халыкка җиткергән көннән 8 дән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.
Гавами тыңлауларда катнашу хокукы белән катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422140, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге, Банк урамы, 17 йорт адресы буенча шәхсән, яисә (Конвертта «Обсуждение Устава» или «Публичные слушания» дигән тамга белән), факс аша (885563) 2-63-21, e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru электрон почта аша җибәрелә.
Заявкалар эш көннәрендә гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм башлыгына тапшырыла.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы рәисе /Р.Җ.Хәмизуллин/